СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2021 Баулы шәһәре № 81

Баулы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставы нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Шәһәр һәм авыл җирлекләре советларының төзекләндерү өлкәсендәге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру тәкъдимнәрен кабул итәргә:

- тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү буенча;
- җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча.

2. Баулы муниципаль районы башкарма комитетына Баулы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
район Советы Рәисе вазыйфасын
башкаручы – район башлыгы
урынбасары, район Советы
Рәисе урынбасары Р.Г. Хәмидуллин